СИШӘМБЕ
26 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 20 (6742)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) нын ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘһӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘһӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Көньяк-Көнбатыш, Көньяк, Дон, Төньяк Кавказ, Воронеж, Калинин, Волхов һәм Ленинград фронтлары гаскәрләре буенча

ВЕРХОВНЫЙ БАШ КОМАНДУЮЩИЙНЫҢ ПРИКАЗЫ

Ике айлык һөҗүм сугышлары нәтиҗәсендә Кызыл Армия киң фронтта немец-фашист гаскәрләрнең оборонасын өзде, дошманның йөз дә ике дивизиясен җимерде, 200 меңнән артык пленный алды, 13.000 орудие һәм башка күп техника кулга төшерде һәм 400 километрга кадәр алга китте. Безнең гаскәрләр җитди җиңүгә ирештеләр. Безнең гаскәрләрнең һөҗүме дәвам итә.

Сталинград янында, Донда, Төньяк Кавказда, Воронеж янында, Великие Луки районында, Ладога күленнән көньяктарак немец-фашист басып алучыларны һәм аларның союзникларын—румыннарны, итальяннарны һәм венгерларны җиңү уңае белән Көньяк-Көнбатыш, Төньяк, Дон, Төньяк Кавказ, Воронеж, Калинин Волхов, Ленинград фронтларының сугышчыларын, командирларын һәм политработникларын котлыйм.

Сталинградка килү юлларында Гитлер армияләрен тар-мар иткән, Ленинград блокадасын өзгән һәм Кантемировка, Беловодск, Морозовский, Миллерево, Старобельск, Котельниково, Зимовники, Элиста, Сальск, Моздок, Нальчик, Минеральные воды, Пятигорск, Ставрополь, Армавир, Валуйки, Россошь, Острогожск, Великие Луки, Шлиссельбург, Воронеж һәм башка күп шәһәрләрне һәм халык яши торган меңнәрчә пунктларны немец оккупантлардан азат иткән командованиегә һәм батыр гаскәрләргә рәхмәт игълан итәм.

Немец оккупантларны тар-мар итү өчен һәм аларны Ватаныбыз чикләреннән куу өчен алга!

Верховный Баш Командующий И. СТАЛИН.

Москва, Кремль, 25 январь, 1943 ел.

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР СТАРОБЕЛЬСК ШӘһӘРЕН АЛДЫЛАР

24 нче январьда КӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ фронт гаскәрләре, кискен атака нәтиҗәсендә СТАРОБЕЛЬСК шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Соңгы сәгатьтә

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР ВОРОНЕЖ ШӘһӘРЕН ТУЛЫСЫНЧА АЛДЫЛАР

25 нче январьда ВОРОНЕЖ фронты гаскәрләре, Воронеж районында һөҗүмгә күчеп, немецларның частьларын аударып ташладылар һәм ВОРОНЕЖ шәһәрен тулысынча алдылар. Шәһәрдән көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак районда Дон елгасының көнчыгыш яры немец-фашист гаскәрләрдән шулай ук чистартылды.

24 нче январьда кичкә таба Воронеж янында плен алынган солдатлар һәм офицерлар саны 11.000 гә артты. Шулай итеп, ВОРОНЕЖ фронты районында плен алынган солдат һәм офицерларның гомуми саны 75.000 кешегә җитте.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

МЕХАНИЗАТОР КАДРЛАР ӘЗЕРЛӘҮ— МӨһИМ БУРЫЧ

1941—1942 нче авыл хуҗалыгы елында республикабыздагы күп кенә МТС лар бик әйбәт эш үрнәкләре күрсәттеләр. Бу, барыннан да элек, МТС лардагы кадрларның, аеруча механизатор кадрларның үз эшләрен белеп һәм яратып башкарулары белән аңлатыла. Чыннан да, эшнең уңышын кадрлар хәл итәләр. Бу инде кагыйдә. Шунлыктан, МТС дирекциясенең һәм МТС политбүлегенең иң мөһим бурычларыннан берсе—ул тракторчылар, комбайнчылар әзерләү булырга тиеш. Бу алар өчен һич тә кичектерелергә ярамый торган бурыч. Чөнки МТС — ул яңа, катлаулы техникага бәйләнгән эре предприятие. Анын уңышлы эше әнә шул техниканы үзләштергән кадрларга бәйләнгән. Әгәр дә тракторчының яки комбайнчының үз эшен җитәрлек дәрәҗәдә белмәве аркасында төзек трактор яки төзек комбайн тик тора икән,—моннан ни мәгънә соң!

МТС эшендә механизатор кадрларның тоткан урыны гаять зур икәнлеге турында әйтеп тә торасы юк. Моны аңлаган урыннарда быел да кадрлар әзерләүгә нык игътибар бирелә. Мәсәлән, Саба МТС ы үзенә кирәкле барлык төр эш буенча кадрлар әзерләү планын арттырып үтәде. Алабуга һәм Буденный МТС лары да кадрлар әзерләү эшендә яхшы гына күрсәткечләргә ирештеләр.

Ләкин, барлык МТС ларда да механизатор кадрлар әзерләү эше уңышлы бара дип уйлау һич тә дөрес булмас иде. Республикабыз МТС ларында меңнәрчә тракторчылар һәм комбайнчылар әзерләнергә тиеш. Бу җиңел эш түгел, әлбәттә. Ләкин шул ук вакытта тулысынча үтәлерлек эш һәм ул бер сүзсез үтәлергә тиеш.

Үткән елгы авыл хуҗалыгы эшләре сезонында республикабызның күп кенә МТС лары үзләренең планнарын үти алмадылар һәм канәгатьләнерлек эшләмәделәр. Тракторчы һәм комбайнчы кадрларның беркадәр җитешмәве һәм күп кенә кадрларның начар өйрәтелгән булулары мондый МТС ларда начар эшләүнең төп сәбәпләреннән берсе булып саналды. МТС дирекцияләренең һәм политбүлекләрнең бурычы үткән елгы хаталарны быел кабатлауга юл куймаудан, механизатор кадрлар әзерләү эшенә җитди игътибар бирүдән гыйбарәт.

Кызганычка каршы, кайбер урыннарда исә тракторчы һәм комбайнчы кадрлар әзерләүдәге үткән елгы хаталар кабатлана. Моны ачык әйтергә мөмкин. Ключи, Аксубай, Зирекле МТС лары үзләре өчен кадрлар әзерләүдә бик акрын кыймылдыйлар һәм бу эш буенча планнарын үтәмиләр. Күп кенә урыннарда тракторчылар һәм комбайнчылар әзерләү курсларына укучылар туплау эшенә әһәмият бирмиләр һәм гамәлдә бу мөһим эшнең үтәлүен өзәләр. Мәсәлән, Алга МТС ы янындагы курсларда укырга тиешле булган кешеләрнең 50 проценты гына тупланган.

МТС лар өчен механизатор кадрлар әзерләү—җитди эш. МТС лар һәм политбүлекләр һәм механизатор кадрлар әзерләү буенча мәктәпләрнең дирекцияләре үзләренең бу өлкәдәге эшләрен кискен рәвештә яхшыртырга, курсларны һәм мәктәпләрне тиешле уку әсбаплары һәм кирәк-яраклары белән тәэмин итәргә, укучыларның тормыш-көнкүреш шартлары турында кайгыртырга тиешләр. Барыннан да элек, укыту эшләренең сыйфатына зур игътибар бирелсен. Укучылар алар өйрәнә торган белгечлекләр буенча җитди рәвештә теория алу белән бергә, практика да алырга тиешләр. Нигездә, укыту эшләренең машина һәм мотор янында, тракторның һәм комбайнның материаль частьлары янында үткәрелүе кирәк. Ниһаять, булачак бу кадрлар арасында политик тәрбия эшләре дә көчәйтелергә тиеш.

ВКП(б) райкомнарының һәм район советы башкарма комитетларының бурычы исә механизатор кадрлар әзерләү эшен контроль астына алудан һәм бу эшне оештыруда җитди булышлык итүдән гыйбарәт. «Шуны истә тотыгыз, иптәшләр, кыенлыклардан курыкмый торган, кыенлыклардан качмый торган, бәлки киресенчә—кыенлыкларны җиңеп чыгу һәм бетерү өчен аларга каршы бара торган кадрлар гына яхшы кадрлар. Кыенлыклар белән көрәштә генә чын кадрлар чыныга» (Сталин). Әнә шундый кадрлар кирәк. Ә бу исә җитди эш таләп итә. 1943 нче елның авыл хуҗалыгы эшләре сезонын МТС лар әнә шундый кадрлар белән каршы алырга тиешләр. Бу, безнең һөҗүм итеп баручы Кызыл Армиябезгә лаеклы җавап булыр.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

24 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

24 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Сталинград** районында, **Воронеждан** көньяктарак, **Төньяк Кавказда, Донның** түбәнге агымы районында, **Төньяк Донец** районында һәм **Ладога күленнән** көньяктарак элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть сугышчылары дошманга каршы төнге сугышта бер ротадан артык гитлерчыларны юк иттеләр. Н-че берләшмә алга таба барып, халык яши торган 3 пунктны алды. Немецлар контратака ясап карадылар, ләкин үтерелгән хәлдә генә дә 300 гә якын солдат һәм офицерларын, шулай ук 6 танкларын югалтып, чигенергә мәҗбүр булдылар.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронтта безнең гвардия частьлары дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп һәм анын контратакаларын кире кайтарып, алга таба киттеләр. Халык яши торган бер зур пункт өчен булган сугышларда немецларның бер батальон пехотасы тар-мар ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Шулар арасында немецлар батальонының командиры да плен алынды. Икенче бер участокта безнең сугышчылар дошман танкларының һәм пехотасының берничә тапкыр ясалган бик каты контратакаларын кире кайтардылар. Немецларның 12 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Ике самоход орудие һәм бик күп личный кораллар кулга төшерелде.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре һөҗүмне дәвам иттерделәр, ә көчләренең бер өлеше белән дошманның туздырылган дивизияләренең аерым группаларын юк итүне дәвам иттерделәр. Халык яши торган бер пункт янындагы урманнарда безнең подразделениеләр 450 немец һәм итальян солдатларын һәм офицерларын плен алдылар. Н-че берләшмә халык яши торган берничә пунктны алды һәм 800 дән артык гитлерчыны юк итте. Икенче бер участокта безнең частьлар 9 паровоз. 20 вагон, азык һәм төрле сугыш милекләре тутырылган 14 склад кулга төшерделәр.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть, дошманның каршылык күрсәтүен бастырып, халык яши торган һәм зур әһәмияте булган бер пунктны алды. 504 автомашина, 14 орудие, 13 пулемет, запас частьлар һәм төрле сугыш милекләре төялгән 70 вагон кулга төшерелде. Пленныйлар алынды. Икенче бер участокта Н-че берләшмә частьлары сугыша-сугыша 20 километр алга киттеләр. Командиры иптәш Вандышев булган подразделениенең разведчиклары дошман тылына үтеп чыктылар һәм күпер астына миналар салып торучы бер группа гитлерчыларны күрделәр. Безнең сугышчылар күперне шартлатырга әзерләнүче барлык немецларны кырып ташладылар.

* * *

Украина партизаннарының Житомир өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отряды немец-фашист басып алучыларга каршы сугышларда 100 гә якын гитлерчыны кырып ташлаган һәм 6 автомашинаны юк иткән. Совет патриотлары шоссе юлларында 8 күперне яндырганнар һәм зур тимер юл күперен шартлатканнар. Украина партизаннарының икенче бер отряды дошманның 3 тимер юл составын юлдан чыгарган. 3 паровоз, сугыш припаслары, техника һәм гаскәр төялгән 37 вагон җимерелгән.

* * *

Ставрополь краенда Воронцово-Александровское шәһәре белән Кипы авылы арасындагы юлда силос чокырларында йөзләрчә совет гражданнарының үле гәүдәләре табылды. Аларны немец-фашист кабахәтләр ерткыч төстә газаплап үтергәннәр. Гәүдәләр теткәләнеп беткән, кайберләренең башларын җимергәннәр, аякларын яндырганнар. Үлекләр арасыннан һөнәр артеле эшчесе 60 яшьлек Антон Запорожцевны һәм туталы-сеңелле Вера һәм Анна Поповаларны танырга мөмкин булды. Гитлерчылар чигенер алдыннан 800 совет гражданын, аларны ирексезләп Германиягә җибәрү өчен, Воронцово-Александровское шәһәренә куып китергәннәр. Колонна шәһәрдән иртәнге сәгать 10 да чыгып китәргә тиеш булган. Килеп җиткән Кызыл Армия частьлары совет гражданнарын гитлерчылар каторгасыннан коткардылар.

* * *

Югославия партизаннары Загреб янындагы Самоборе шәһәрендә немецлар гарнизонына һөҗүм ясаганнар. Бик каты сугышта 200 гә якын гитлерчы юк ителгән. Баня-Лука шәһәре районында партизаннар Манячу тавын дошманнан чистартканнар. Яйце шәһәреннән ерак түгел генә Югославия патриотлары немецларның бер батальон пехотасын тар-мар иткәннәр. Партизаннар күп кораллар, сугыш припаслары һәм сугыш снаряжениесе кулга төшергәннәр.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

24 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

24 нче январьда Көньяк Көнбатыш фронт гаскәрләре, кискен атака нәтиҗәсендә, Старобельск шәһәрен һәм тимер юл станциясен, халык яши торган зур пунктлардан Павловканы, Шульгинканы, Бахмутовканы һәм тимер юл станциясе Красноозеровканы алдылар.

Закавказье фронты гаскәрләре район үзәкләреннән Песчанокопскоены, Молотовскоены, халык яши торган зур пунктлардан Красная Полянаны, Ново Михайловскоены, Безопасноены, Краснооктябрьскоены, Каменнобродскаяны, Воскресенскаяны һәм тимер юл станциясе Песчанокопскаяны алдылар.

17 нче январьдан 23 енә кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында немецларның 162 самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 75 самолет югалттык.

1 нче январьдан 15 енә кадәр Төньяк флот авиациясе Баренц диңгезендә дошманның барлыгы 51.000 тонна авырлыктагы 9 транспортын һәм бер сакчы кораблен батырды.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп һәм аның контратакаларын кире кайтарып, элекке юнәлешләрдә һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер участокта немецлар контратакага пехота һәм 40 ка якын танк җибәрделәр. Баштарак дошман безнең подразделениеләрне бераз кысрыклый алган иде. Совет сугышчылары, дошманны хәлсезләндереп һәм немецларның 10 танкысын юк итеп, контрудар белән гитлерчыларны алып ташладылар һәм элекке хәлне кайтардылар. Н-че берләшмә халык яши торган 6 пунктны алды һәм хәзер дошманны куып бара.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр. Н-че гвардия часте дошманның каты каршылык күрсәтүен бастырып, Старобельск шәһәрен алды. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең танкистлар бер тимер юл станциясенә кыю һөҗүм ясадылар, немецлар пехотасы төялгән ике эшелонны тар-мар иттеләр һәм дошманның бер бронепоездын сафтан чыгардылар.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре уңышлы һөҗүм алып бардылар. Безнең танкистлар дошманның чолганып алынган частьларының таркатылган группаларын юк итүне дәвам иттерделәр. Бер көн эчендә 1.600 кеше пленг алынды. Халык яши торган Волоконовка пункты гарнизоны коралын ташлаудан баш тарткан иде. Гарнизон бөтенләй юк ителде. Н че часть сугышчылары халык яши торган бер зур пунктны алдылар. Бу пункт урамнарында дошманның 360 үле гәүдәсе калды. Бу пункт өчен булган сугышларда 18 орудие, 32 пулемет, 7 миномет, бер сугыш припаслары склады һәм ике азык склады кулга төшерелде.

* * *

Закавказье фронтында Н че берләшмә сугышчылары алга киттеләр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Армавир шәһәренә килү юлларында булган сугышларда 600 гә якын гитлерчы кырылды, дошманның 8 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Н-че часть халык яши торган бер пунктның читендә күп санлы ныгытмаларны җиңеп үтеп, бу пунктның урамнарына бәреп керде. Бик каты штык бәрелешләре нәтиҗәсендә безнең сугышчылар бу пунктны алдылар. Сугыш кырында дошманның сафтан чыгарылган 4 танкысы, 6 орудиесе, 15 автомашинасы, 17 пулеметы, күп винтовкалары, гранаталары һәм башка кораллары калды. Фураж һәм азык тутырылган 3 склад кулга төшерелде.

* * *

Ленинград өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отрядның бер группа партизаннары дошманның фронт линиясенә бара торган бер хәрби эшелонын һәлак итүне оештырганнар. Бер. паровоз, автомашиналар төялгән 2 платформа, сугыш припаслары һәм снаряжение төялгән 14 вагон җимерелгән. Бу отряд партизаннарының икенче бер группасы 42 гитлерчыны кырып ташлаган һәм ике азык складын яндырган.

* * *

Немец гаскәрләре Совет — Германия фронтында гаять зур югалтуларга дучар ителгәнлектән, немецлар командованиесе оккупацияләнгән илләрдәге дивизияләрен Көнчыгышка күчерә. Көньяк Көнбатыш фронтның бер участогында немецларның 304 нче пехота дивизиясенең 575 нче полкыннан обер ефрейтор Альберт Кюппе һәм солдат Конрад Фогель плен алындылар. Пленныйлар болай диделәр: «Безнең полк Франциядә оккупация гаскәрләре составында иде. Үткән елның 15 нче декабрендә полк Дюнкерктан китәргә приказ алды. Безнең кая баруыбызны бер кем дә белмәде. Тик юлда гына без үзебезне Россиягә алып баруларын төшендек. Полк башлыча, олыгайган солдатлардан оештырылган иде. Руслар белән булган беренче бәрелештә үк полкның ике батальоны авыр югалтуларга дучар ителде».

Немецларның 7 нче танк дивизиясенең моторлаштырылган 7 нче гренадер полкыннан плен алынган обер ефрейтор Гейнц Байер болай диде: «7 нче танк дивизиясе Франциядә. Бордо районында иде. 1942 нче елның декабрь уртасында дивизия бөтен составы белән Көнчыгыш фронтка китте. Без бик озак бардык. Станцияләр барысы да тулган иде, паровозларның бик нык җитешмәве сизелә иде. Тик 5 нче январьда гына безнең полк фронт линиясеннән 40—50 километр ераклыктагы бер тимер юл станциясенә килеп туктады».

* * *

Түбәндә Ростов өлкәсенең Балабановка авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немецларның авыл аркылы үтеп киткән танк часте гражданнар халкын ерткыч төстә җәзалады. Немец полковнигы приказы буенча гитлерчылар 17 колхозчы семьясын сайлап алып, аларны авыл читенә алып чыктылар һәм шунда пулеметтан атып үтерделәр. Бер көн эчендә фашист палачлар хатын кызлардан, балалардан, картлардан һәм авырулардан 85 кешене аттылар. Немецлар йортларга бәреп керделәр һәм халыкны таладылар. Талаулар гражданнар халкын коточкыч төстә мыскыллаулар белән барды». Актка Балабановка авылы кешеләреннән А. Демьяненко, Д. Райшакова, А. Кучмаев һәм хәрби хезмәткәрләрдән майор Облак, капитан Курочкин һәм 3 нче ранг хәрби врач Есиповичлар кул куйды.

25 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

25 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр Сталинград районында, Воронеждан көньяктарак. Төньяк Кавказда, Донның түбәнге агымы районында, Төньяк Донец районында һәм Ладога күленнән көньяктарак элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть немецларның контратакасын кире кайтарды һәм чигенүче дошманның артыннан куып барып, халык яши торган пәм көчле рәвештә ныгытылган бер пунктка бәреп керде һәм аны алды. Сугыш кырында немецларның яндырылган 3 танкысы калды. 2 самоход орудие, бер бронемашина, 11 пулемет, 3 миномет, 39 автомат, күп винтовкалар һәм сугыш припаслары кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең сугышчылар халык яши торган 2 зур пунктны алдылар.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронт гаскәрләре һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер пункт янында аеруча каты сугышлар булды һәм ул берничә тапкыр кулдан кулга күчте. Төнлә белән безнең сугышчылар немецларга атака ясадылар һәм штык сугышында дошманны тар-мар иттеләр. Бер батальонга якын пехоталары үтерелгәч һәм яралангач гитлерчылар чигенделәр Безнең гаскәрләр бер сугыш припаслары склады, бер ашлык склады, 46 автомашина һәм күп кораллар кулга төшерделәр.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар. Дошман гаскәрләренең чолганып алынган тагын бер группасы бетерелде. 1.100 дошман солдаты һәм офицеры плен алынды. 260 автомашина, 15 орудие, 48 пулемет һәм 13 миномет кулга төшерелде. Н-че часть сугышчылары каты сугыш нәтиҗәсендә, халык яши торган бер пунктны алдылар һәм танкка каршы ата торган 4 орудие, 17 пулемет, 19 автомат, танклар өчен запас частьлар саклана торган бер склад һәм 2 радиостанция кулга төшерделәр.

* * *

Закавказье фронты гаскәрләре халык яши торган берничә дистә пунктны алдылар. Гвардияче казаклар сугыша-сугыша 30—40 километр алга киттеләр һәм 800 гә якын гитлерчыны юк иттеләр. 100 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары плен алынды. 7 орудие, сугыш милекләре төялгән 40 автомашина һәм 50 повозка, 2 сугыш припаслары склады, шулай ук немецлар тарафыннан халыктан талап алынган 2.000 баш мөгезле терлек һәм 15.000 сарык кулга төшерелде.

* * *

Орел өлкәсендә хәрәкәт итүче, Щорс исемендәге отрядның партизаннары өч көн эчендә немецларның 3 хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә 3 паровоз, 21 вагон һәм автомашиналар төялгән 5 платформа җимерелгән. Һәлакәт вакытында 200 ләп немец солдатлары һәм офицерлары үлгән һәм яраланган. Икенче бер отрядның партизаннары дошманның бер гарнизонына һөҗүм иткәннәр. Бик каты штык сугышында 67 гитлерчы юк ителгән.

Ленинград өлкәсе, Демянск районы, Глухое Демидово авылы кешеләреннән Семен Мартынов, Артемий Волков һәм Петр Елин немец-фашист кабахәтләренең ерткычлыклары турында түбәндәгеләрне сөйләделәр: «Гитлерчылар авылдагы бөтен халыкны таладылар. Беренче көннәрдә үк немецлар крестьяннарның терлекләрен, ашлыкларын, яшелчәләрен һәм башка продуктларын талап алдылар һәм халыкны ач үлемгә дучар иттеләр Бағлык ирләрне һәм хатын-кызларны, шулай ук балаларны да тәүлегенә 14—16 шар сәгать буена ныгытмалар төзелешендә эшләргә мәҗбүр иттеләр Фашист ерткычлар крестьяннарны мыскылладылар һәм чыбыклар белән суктыру җәзасын керттеләр. Аз гына вакыт эчендә авылда 40 тан артык кеше ачлыктан үлде»

* * *

Франциянең Лион шәһәрендә азат укчылар немецларның хәрби эшелонына атканнар. Жанлиста бер группа французлар бер поездны һәлак итүне оештырганнар. Немец солдатлары утырган 5 вагон елгага авып төшкән Амьенда гитлерчылар белән тулган бер ресторанда шартлау булган. Берничә дистә немец үлгән һәм яраланган.

ТАТАР КЫЗЫ

— Мине алгы линиягә җибәрегез әле, —диде Суфия Хәйретдинова.

Батальон командиры Просвиркин уйланып, аңа туры карап, бераз эндәшмичә торды да:

— Ә курыкмассызмы соң анда?—дип сорау бирде.

— Юк, курыкмам. Куркырлык булгач фронтка килмәс идем дә.

... Сугыш кыры. Бөтен тирә-якны үлем уты кочып алган. Пулялар, снарядлар, бомбалар, миналар выжылдап, сызгырып очалар, һаваны һәм җирне тетрәтеп шартлыйлар, үзләренә корбаннар эзлиләр... Командирның «Курыкмассызмы соң анда» дигән сүзләрен хәтерләде ул. Курку турында уйласаң чыннан да куркыныч икән монда. Ләкин ул турыда уйламаска кирәк. Хәер, курку турында уйларга вакыт та юк. Кеше турында. Ватан турында, үз Ватаннарын саклау өчен үлем уты эченә кергән ил батырлары турында уйлаудан бүтән, яраланып сафтан чыкканнарның тормышларын саклап калудан бүтән төрле уйлар башка һич тә кермиләр бу утлы сугыш кырында.

Тартыныбрак ыңгырашкан тавыш ишетелә. Суфия тизрәк шунда ташлана. Сугышчы Семенов Аягы каты яраланган, сынган. Авыр аңа. Аның хәлен җиңеләйтергә кирәк. Суфия аңа перевязка ясый, санбатка озата. Әрнеткеч авыртудан бозылып чытылган. ямьсезләнгән чырай әкренләп алсулана һәм матур итеп елмая башлый. Ул Суфияга чын күңелдән рәхмәтләр әйтә Җанланып киткән күзләрен тулы ачып, сокланып, тирән ихтирам белән карый ул Суфияга. Күрсәткән бик кечкенә хезмәтен өчен моннан да зур рәхмәт алу мөмкинме соң!

Суфия фронтның алгы линиясендә бик күп тапкырлар булды. Һәм анда ул үзенең кирәкле кеше итеп тапты. Күп кенә сугышчыларны үлем кочагыннан тартып, үз кочагына алды ул, тормыш кочагына кайтарды. Бик күп сугышчыларның авыр хәлләрен җиңеләйтте, егылганнарны аякка бастырды, ыңгырашучыларны елмайтты, елаучыларны көлдерде ул...

— Эш шул кадәр күп анда, һәм ул эш сине шул кадәр рухландыра, ашкындыра— ашау-эчүне дә, ялны да, йокыны да онытып җибәрәсең...—ди Суфия.

* * *

Санчастька бер партизан малай йөгереп килеп керде.

— Әнә анда, күлнең теге ягында,— диде ул, арганлыктан сулышын көчкә алып,—урманда, бер кыз яраланып ята... Ул партизанка... Немецлар турында төрле хәбәрләр алып кайтканда минага бәрелгән...

Частьның өлкән санинструкторы Суфия Хәйретдинова, үзе белән бергә ике сугышчыны алып бу бик таныш малай артыннан ияреп китте Көймәгә утырып күлнең аръягына чыктылар Якында гына урман Немецлар позициясе.

Юлда часть штабы начальнигы очрады.

— Бу урыннар барысы да миналанган,— диде ул.—Бик сак булыгыз.

Малай күрсәткән урынга ничек уңай барып җитәргә өйрәтте аларны. Ике сугышчы алдан китте. Суфия алардан калышмады.

Партизан малай кирәкле урынга бик тиз алып чыкты аларны. Килеп җиттеләр. Мина шартлаудан авыр контузия алып, хәлсез, һушсыз калган партизанка сузылып ята. Аны да бик тиз таныдылар.

— Тизрәк штабка!—дия алды ул.

Суфия аңа беренче ярдәмне күрсәтте. Аны тынычландырды. Читкә бер генә адым атлаган иде ул—кинәт нәрсәдер бик каты шартлап китте. Тагын мина... Бу юлы Суфия үзе мина корбаны булды. Аның аягы бик нык яраланды.

— ...Белсәгез иде никадәр шатлык!— ди, хәзер госпитальдә дәваланып ятучы Суфия иптәш.—Партизанканы коткардым мин. Ә ул немецлар турында безнең штабка нинди кыйммәт мәгълүматлар алып кайткан!

* * *

Ватаны алдында үзенең бурычын алгы линиядә торып намус белән үтәгән, тыйнаклы, үзе турында сөйләргә яратмаучы, тартынучан холыклы бу татар кызы Суфия кем соң ул?

Без аны, шулай да, үзе турында аз гына булса да сөйләтә алдык.

Сафия Галимҗан кызы Хәйретдинова Олы Тархан районының Бакырчы авылында туган. Аңа нибары 21 генә яшь әле. 1935 нче елга ·кадәр колхозда эшләгән. Шуннан соң Суфия Казанга килгән һәм 3 нче мех фабрикасында скорнячка булып эшләгән.

Хезмәттә алдынгы стахановчы, фабрика тормышында гына түгел, бөтен Ватан тормышында актив катнашучы яшь татар кызы, производстводан аерылмыйча, медсестралар мәктәбендә укып һәм аны яхшы тәмамлап, бөек Ватан сугышы фронтына китә. Данлыклы Ленинградны саклауда катнаша ул

Үзен тәрбияләп үстергән сөекле Ватанын явыз дошманнардан саклау эшенә барлык тормышын. гүзәл яшьлеген, саф һәм ялкынлы мәхәббәтен бөтен тулылыгы, бөтен дәртлелеге белән багышлаган татар кызы Суфия Хәйретдинова белән хәзер безнең барлык укучыларыбыз да таныш булырлар инде. Һәм алар да аңа чын күңелдән рәхмәт әйтерләр. Суфиядан үрнәк алып, үзләренең яшьлекләрен аның гүзәл юлы буйлата юнәлдергән безнең бик күп Суфияларыбыз, Сәлимәләребез, Нәфисәләребез—үз халкының иң яраткан, иң кадерле кызлары булачаклар.

ГАЗИЗ ИДЕЛЛЕ.



«Гидродвигатель» артелендә. Рәсемдә: 7 нче номерлы һөнәр училищесы укучыларыннан В. Виноградов, Н. Гегункин, В. Филимонцев һәм В. Смирновлар. Алар зурлар нормасын 200 процентка үтәп киләләр.

С. Парфенов фотосы.

ЯРЫШТА АЛДЫНГЫ ЯШЬЛӘР

Оборона Халык Комиссары иптәш Сталинның Беренче Май приказына, Хезмәт резервларының баш идарәсе һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты чакыруына җавап итеп, илебездәге һөнәр һәм тимер юл училищеларының, ФЗӨ мәктәпләренең Бөтенсоюз социалистик ярышы гаять зур күтәренкелек белән башланып китте һәм киң җәелде.

Татарстандагы училищеларның һәм ФЗӨ мәктәпләренең коллективлары бу ярышка бердәм рәвештә кушылып, ярышның төп шартлары нигезендә, үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алдылар.

1 нче номерлы тимер юл училищесы, 2 нче һәм 3 нче номерлы һөнәр училищелары декабрь аендагы ярышта республикабыз күләмендә беренче урынны яулап алдылар. 1 нче номерлы тимер юл училищесы (директоры иптәш Казаков, политчасть буенча урынбасары Токмянин, ВЛКСМ комитеты секретаре Попов) декабрь аенда түбәндәге уңышларга ирешә: укучылар составы тулысынча сакланып калынды; махсус заказлар башкару планы 180 процентка үтәлде; производство өйрәнүләре буенча отлично һәм яхшы билгеләре 64 процент һәм гомуми өлгереш—99,7 процент булды. Декабрь аенда укучыларның үз көчләре белән ашханәгә ремонт ясалды һәм яңа слесарьлык цехы җиһазландырылды. Мастерскойлар, тулай торак һәм ашханә үрнәк төстә тотыла. Укучыларның барысы да хәрби әзерлек занятиеләренә тартылганнар һәм 100 процент өлгереш бирәләр. Хәрби әзерлек буенча отлично һәм яхшы билгесе алучылар 69 процент тәшкил итә. Бу училище Татарстан Хезмәт резервлары идарәсенең һәм ВЛКСМ Өлкә Комитетының күчмә Кызыл Байрагын 7 ай буе рәттән үз кулында нык саклап килә. «Юдино комсомолецы» исемле бронепоезд өчен средстволар җыюны беренче булып бу училище башлап җибәрде. Училищенең укучылары һәм работниклары арасында 10 нчы январьга кадәр вакыт эчендә 20 мең сум акча җыелды да инде.

3 нче номерлы һөнәр мәктәбе (директоры Нестерова, политчасть буенча урынбасар Крутиков, ВЛКСМ комитеты секретаре Петров) декабрь аенда фронт заказларын 191 процентка үтәде, гомуми өлгереш 99,5 процент, отлично һәм яхшы билгесе алучылар 83 процент тәшкил итте. Ашханә һәм тулай торак отлично хәлдә һәм мастерскойлар яхшы хәлдә тотылалар. Хәрби-физкультура эшләре буенча да (җитәкчесе комсомолец Бровкин) училище беренче урынны алып тора.

2 нче номерлы һөнәр училищесы да (директоры Амелин, политчасть буенча урынбасар Романенко, ВЛКСМ комитеты секретаре Столярова) үз эшендә яхшы гына уңышларга ирешә. Укучыларның өлгерешe—99,4 процент, отлично һәм яхшы билгесе алучыларның саны 74 процент булды. Производствода өйрәнү барышында укучылар катлаулы һәм җаваплы бер заказны 132,2 процентка үтәделәр.

Декабрь аенда 7, 8, 9, 10 нчы номерлы һөнәр училищеларының һәм 1, 2, 5, 14, 24 нче номерлы ФЗӨ мәктәпләренең коллективлары да яхшы нәтиҗәләргә ирештеләр. Н-че номерлы тимер юл училищесының иптәш Горожанин җитәкчелегендәге 10 нчы группасы, 10 нчы номерлы һөнәр училищесының комсомолец иптәш Куинов җитәкчелегендәге 8 нче группасы декабрь аенда аеруча зур уңышларга ирештеләр.

Уку-өйрәнү һәм производство стахановчыларының сафлары айданайга үсә. Мәсәлән, П. Зверев (1 нче номерлы тимер юл училищесы) «Хезмәт резервлары отличнигы» грамотасы белән бүләкләнгән. Ф. Шәфиков (2 нче номерлы тимер юл училищесы), В. Ионенко (1 нче номерлы һөнәр училищесы), Н. Елизаров (3 нче номерлы һөнәр училищесы), М. Рогатова (11 нче номерлы һөнәр училищесы) һ. б. иптәшләр бөтен эштә гүзәл үрнәкләр күрсәтәләр, планнарны 200—380 процентка үтиләр.

Горький шәһәренең 1 нче номерлы һөнәр училищесы коллективының чакыруына җавап итеп, республикабызның училищелары һәм ФЗӨ мәктәпләре үз өсләренә яңа йөкләмәләр алдылар. Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган социалистик ярышка актив кушылдылар. Укучы яшьләр фронтка ярдәмгә үзләренең барлык көчләрен биреп укыйлар, өйрәнәләр, эшлиләр.

Ләкин училищелар һәм ФЗӨ мәктәпләре алдында зур бурычлар тора әле. Уку-өйрәнүләрнең сыйфаты, эш темплары тагын да югары күтәрелергә, фронтка ярдәм тагын да көчәйтелергә тиеш. Кызыл Армиянең 25 еллыгын без яңа, зур җиңүләр белән каршыларга, Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын яулап алырга, бөтен Союз күләмендә беренче урынга чыгу өчен көрәшергә тиешбез.

А. ФИЛИМОНОВА.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК ЭШЛӘРЕ КИҢ ҖӘЕЛДЕРЕЛДЕ

Иптәш Сталинның Татарстан АССР колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына җибәргән котлау телеграммасы Кызыл юл районы колхозчылары арасында зур политик производство активлыгын тудырды.

Соңгы көннәрдә барлык колхозларда да митинглар үткәрелде. Колхозчылар 1943 нче елгы язгы чәчүгә яхшы итеп әзерләнү буенча конкрет йөкләмәләр алдылар. Орлыклык участокларыдан җыеп алынган чәчүлек орлыкларны чистарту һәм аларны район орлык лабораториясендә тикшерү эшләре киң җәелдерелде. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау, агротехника чаралары планын үтәү, атларны язгы чәчүгә яхшы итеп әзерләү оештырылды. Район буенча 15 нче январьга 4.830 центнер орлык чистартылды. 12 колхозда орлык чистарту эшләре тәгамләнде инде. Барлыгы 12.350 гектарда кар тоту чаралары үткәрелде. Басуга 7.474 тонна тирес чыгарылды. 850 центнер фикали һәм 482 центнер кош тизәге җыелды. 13 колхоз 15 нче январьга кар тоту планын тулысынча үтәделәр. Күп кенә колхозларда кар тоту планы арттырып үтәлде. Мәсәлән, «Трактор» колхозы (председателе иптәш Әхмәдуллин) кар тоту планын 128 процентка үтәде, кырга 200 йөк тирес чыгарды, агротехника түгәрәкләре оештырды. Бу түгәрәкләргә язгы чәчү эшләрендә катнашырга тиешле колхозчыларның барлыгы да йөриләр. «Октябрь» колхозы (председателе иптәш Гыйльфанов) кар тоту планын 103 процентка, Калинин исемендәге колхоз (председателе иптәш Шиһапова) 108 процентка һәм Иске Өҗем колхозы 123 процентка үтәделәр.

ВКП(б) райкомы 4 нче январьда тимерчеләрнең район киңәшмәсен үткәрде. Киңәшмәдә 32 кеше катнашты. Алар барлык машиналарны яхшы сыйфатлы итеп ремонтларга йөкләмә алганнар иде. Тимерчеләр хәзер бу йөкләмәләрне үтәү өстендә тырышып эшлиләр. Район буенча 80 данә атлы чәчү машинасы һәм 630 данә атлы сабан һәм 183 культиватор, 850 тырма ремонттан чыкты. Молотов исемендәге колхозның ватан сугышы фронтыннан кайткан тимерчесе Габдерахман иптәш Фәйзерахманов Кызыл Яр авыл советына караган Калинин һәм Куйбышев исемендәге колхозларның авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны тәгамләде. Хәзер иптәш Фәйзерахманов авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау өчен Иске Өҗем колхозына китте.

Язгы чәчүдә атлардан дөрес файдалану һәм аларны бу эшкә яхшы итеп әзерләү мәсьәләләре буенча 9 нчы январьда район җир бүлеге зоотехника һәм ветеринария работникларының катнашы белән колхозлардагы ат караучыларның һәм ветеринария работникларының район киңәшмәсен үткәрде.

Язгы чәчүгә әзерлектә колхозларга практик булышлык күрсәтү өчен район активы арасыннан 40 кеше колхозларга җибәрелде.

М. ХӘЙРЕТДИНОВ,
ВКП(б) райкомы секретаре.

Язгы чәчүгә әзерлек

ЧИСТАЙ, 23 январь. (**Телефон буенча**). Тельман исемендәге колхоз членнары язгы чәчүгә яхшы әзерләнәләр. Алар бу эшне Кызыл Армиянең 25 еллыгына кадәр тулысынча тәгамләү өчен көрәшәләр. 56 тырма, 8 культиватор, 8 чәчү машинасына ремонт ясалды. Шулай ук камыт, дилбегә һәм башка инвентарьлар төзәтелде.

Орлык чистарту да яхшы оештырылган. 120 центнер бодай, 104 центнер солы чистартылып, коры урынга салып куелган. Тимерче иптәш Кәримуллин ремонтта бер үзе эшләп, зур тырышлык күрсәтә. Ул көнлек норманы 200 процентка кадәр үти.

Кырга 600 йөк тирес чыгарылган. Көл, кош тизәге һәм башка җирле ашламаларны туплау дәвам итә.

СВОДКА

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче ЕЛНЫҢ 20 нче ЯНВАРЕНА
(ПЛАНГА КАРАТА ПРОЦЕНТЛАРДА)

МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	95,7
2. Нөркәй	94,3
3. Чокалы	90,9
4. Ишеево	80,0
5. Чүпрәле	79,1
6. Бөгелмә	78,7
7. Тирсә	77,5
8. Тымытык	75,7
9. Саба	74,0
10. Алабуга	70,5
11. Норлат	64,3
12. Юртыш	64 3
13. Тархан	63,9
14. Октябрь	63,8
15. Сарман	62,3
16. Мөрәле	61,7
17. Актаныш	61,4
18. Яниль	61,4
19. Чистай	60,8
20. Кызыл Чапчак	60,7
21. Азин	59,5
22. Зөя	59,5
23. Соколка	58,8
24. Дәүләки	58,7
25. Заинский	58,6
26. Кызыл йолдыз	58,3
27. Кузайкино	58,2
28. Кадряк	56,8
29. Поповка	56,1
30. Мәлки	56,0
31. Алга	55,0
32. Беренче Май	54,9
33 Олы Кариле	54,0
34. Чыбыклы	53,3
35. Чүрибураш	53,2
36. Әлмәт	52,1
37. Дөбьяз	52,1

МТС лар	Үтәлеш
38. (Мөслим Чистай)	50,0
39. Б. Матак	49,0
40. Димитров	48,6
41. Баулы	48,1
42. Ютазы	48,0
43. Тәтеш	47,9
44. Бондюг	46,7
45. Юдино	46,7
46. Кукмара	46,4
47. Куйбышев	45,6
48. Т. Тамак	43,6
49. Исәнбай	43,2
50. Тельман	42,6
51. Чаллы	41,8
52. Иске Чишмә	40,9
53. Буа	40,7
54. Чаллы	40,5
55. Калинин	40,0
56. Рождественский	39,1
57. Зирекле	38,4
58. Иске Писмән	38,3
59. Кичү	38,1
60. Акташ	37,9
61. Яңа Чишмә	37,3
62. Иске Тимошкино	36,8
63. Балтач	36,5
64. Карамалы	36,4
65. Әтнә	36,0
66. Аксубай	35,7
67. Черемуховский	35,2
68. Буденный	35,1
69. Алексеевский	34,8
70. Теләче	34,7
71. Маткавыш	34,5
72. Питрәч	34,0
73. Каргалы	33,3
74. Әхмәт	34,3

МТС лар	Үтәлеш
75. К. Тамагы	33,3
76. Кәкре елга	32,8
77. Минзәлә	32,6
78. Биләр	31,7
79. Морт	31,4
80. Кызыл юл	31,1
81. Казанбаш	30,3
82. Шишмә	30,3
83. Шөгер	30,2
84. Арча	30,2
85. Балык бистәсе	30,0
86. Ромадан	29,6
87. Стоблище	29,6
88. Солтан	29,4
89. Салман	28,9
90. Әлши	28,6
91. Макыл	28.3
92. Тәкәнеш	28,3
93. Константиновка	26,9
94. Трехозерский	26,4
95. Майдан	25,9
96. Кузнечиха	25,4
97. Биектау	25,0
98. Мамадыш	21,0
99. Әлки	17,9
100. Үзәк	17,6
101. Тат. Ходяш	16,7
102. Зур Поляна	15,8
103. Тат. Ялтан	15,2
104. Кошкино	13,0
105. Чиябаш	11,1
106. Ключи	10,3
Барлыгы:	43,7
1943 нче елның 15 нче январена	39,6



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. (Үзәк фронт). Рәсемдә: Атлы-гвардия дозоры.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

25 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

25 нче январьда **Воронеж** фронты гаскәрләре, Воронеж районында һөҗүмгә күчеп, немецларның частьларын аударып ташладылар һәм **Воронеж** шәһәрен тулысынча алдылар.

Көньяк көнбатыш фронт гаскәрләре район үзәге **Лозно-Александровканы** һәм халык яши торган күп кенә башка пунктларны алдылар.

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр халык яши торган пунктлардан **Красный Манычны, Журавлевканы, Благодатнаяны** алдылар.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр район үзәге һәм тимер юл станциясе **Белая Глинаны,** халык яши торган зур пунктлардан **Кармалиновскаяны, Фельдмаршальскийны, Привольныйны, Ново Кубанскоены** алдылар.

Баренц диңгезендә безнең корабльләр дошманның бер миноносецын батырдылар.

* * *

24 нче январьда безнең авиациябез дошман портында немецларның 10.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырды һәм фронтның төрле участокларында 6 артиллерия батареясының утын бастырды, 4 сугыш припаслары складын шартлатты, 2 тимер юл составын җимерде һәм ике ротага якын дошман пехотасын таркатты һәм бер өлешен юк итте.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н че берләшмә сугышчылары, немецларның күп санлы оборона корылмаларын җиңеп, халык яши торган бер зур пунктның урамнарына бәреп керделәр. Бик каты сугышта 400 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Немецларның 11 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде. Донның түбәнге агымы районында безнең частьлар дошман танкларының һәм пехотасының контратакаларын кире кайтардылар. Бу сугышларда немецларның ике батальон пехотасы тар мар ителде, 9 танкысы зарарланды һәм яндырылды.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронтта совет гаскәрләре һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бер участокта безнең частьлар дошманның мотопехотасына һәм танкларына каршы каты сугышлар алып бардылар. Немецларның барлык контратакалары алар өчен зур югалтулар белән кире кайтарылды. Старобельск шәһәренә штурм ясаган чакта 1.000 нән артык гитлерчы кырып ташланды. Шәһәрдә безнең частьлар 15 танк, 16 бронемашина, 50 орудие, 200 дән артык автомашина, 8 зур склад, 8 паровоз, бик күп вагоннар һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. 300 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары плен алынды.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре Воронеж шәһәрен тулысынча алдылар.

Воронеж фронтының башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм операцияләрен дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Халык яши торган бер зур пунктта дошман гарнизоны юк ителде. 2.000 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары плен алынды. 250 автомашина, 300 ат, сугыш припаслары һәм азык складлары кулга төшерелде. Икенче бер участокта совет частьлары дошманның каршылык күрсәтә торган әһәмиятле үзелын алдылар. 3 танк, 28 орудие һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Закавказье фронты гаскәрләре сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че часть немецларның танкка каршы дивизионын тар-мар итте. Танкка каршы ата торган 20 орудие сафтан чыгарылды һәм 7 орудие кулга төшерелде. 80 пулеметый алынды. Икенче бер участокта иптәш Биляев командалыгындагы безнең сугышчылар дошман кулындагы бер пунктка бәрып чыктылар һәм немецлар батальонының штабын тар-мар иттеләр. Трофейлар һәм кыйммәтле документлар кулга төшерелде.

* * *

Ленинград өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отрядның бер группа партизаннары немецларның хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт вакытында бер паровоз һәм сугыш припаслары төялгән 10 вагон җимертелгән. Поездлар хәрәкәте бер тәүлеккә тукталып торган. Немецлар тимер юлны төзәткәннәр һәм сакчыларны көчәйткәннәр. Берничә көннән совет патриотлары шул ук участокта дошманның ягулык төялгән эшелонын һәлак итүне оештырган. Бер паровоз һәм 8 цистерна юк ителгән. Бу линиядә поездлар хәрәкәте яңадан тукталган

* * *

Сталинград районында сугыш кырында немецларның 305 нче пехота дивизиясе составындагы 578 нче полкның 10 нчы ротасы ефрейторының куен дәфтәре табылды. Түбәндә шул куен дәфтәреннән өзекләр китерелә: «...Шосседә басып торабыз, нәрсә эшләргә белмибез. Мин бик ачыктым. Бер каян да бер кашык аш таба алмыйм. Бер кечкенә авылга барып җиттем. Монда чын мәгънәсе белән җәһәннәм... Көчкә генә үз ротамны эзләп таптым һәм терлек абзарында кундым. Бик туңдым. Минем бөтен әйберләремне урладылар... Тагын марш, тагын азыксыз. Кич белән, авыр марштан соң, Сталинградка килдек. Бер базга төшәргә туры килде. Анда 30 кеше Кыргый кешеләр. Һәркемнең нервсы какшаган. Ашау өчен өзлексез ызгыш һәм сугыш. Ачлыкниләр генә эшләми! Безнең янда яралылар һәм дизентерия белән авыручылар бар. Алар үләләр. Аларның ачтан үлмәслек генә итеп бирелгән паекларын таза солдатлар талап алалар, туп туры авызларыннан йолкыйлар... Мин яшәргә телим. Ничек кенә итеп булса да яшәргә. Бөтенесен шайтан алсып, тик исән генә каласы иде.... Чокырда бер солдат белән утырам. Ул 20 яшьлек егет. Австриядән. Беребез дә бер сүз дә әйтми. Нәрсә турында сөйләргә? Миңа бик салкын. Яралыларның ыңгырашулары ишетелә. Алар кар өстендә, көртләрдә аунап яталар. Аларны җыймыйлар, алып китмиләр... Мин бу коточкыч җәһәннәмнән котылу өчен пленга бирелүдән башка юл күрмим».

МОНРЕАЛЬДА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ БЕЛӘН ТЕЛӘКТӘШЛЕК МИТИНГЫСЫ

ОТТАВА, 23 январь. (ТАСС). «Канаданың Россиягә ярдәм фонды» дигән җәмәгать комитеты Монреальда митинг оештырды. Митингта 12.000 кеше катнашты. Бу митинг Советлар Союзына Канада халкы күрсәтә торган симпатиянең ачык демонстрациясе булды. Канаданың баш министры Маккензи Кинг һәм митингта катнашу өчен килгән АКШ президенты хатыны Эльонора Рузвельт, Квебек провинциясенең баш министры Годбаут һәм Канаданың башка күренекле эшлеклеләре митингта речь сөйләделәр. Митингка килгән почетлы кунаклар арасында СССР ның Канададагы илчесе иптәш Гусев та бар иде.

Канаданың баш министры Маккензи Кинг митингта Канада генерал-губернаторы тарафыннан җибәрелгән котлау хатын укыды. Бу хатта Советлар Союзына һәрьяклап ярдәм күрсәтергә кирәклеге күрсәтелә.

Эльонора Рузвельт үзенең чыгышында болай диде: «Бүген без союзнигыбыз Советлар Союзына тиешле бәяне бирәбез. Руслар үзләренең җирләрендә безнең гомуми дошманыбызга каршы бик яхшы көрәш алып бардылар һәм алып баралар. Мин беркайчан да Россиядә булганым юк, ләкин үз тарихларының беренче көннәреннән үк руслар үз илләренә бөек мәхәббәт белән карадылар һәм туган җирләрен гаять зур батырлык белән сакладылар».

Англиядә Советлар Союзына ярдәм кампаниясенең бик уңышлы барганлыгын күрсәтеп, Эльонора Рузвельт, руслар хәзерге вакытта Германия авиациясенең тупланган куәтенә каршы башлыча көрәш алып баралар һәм шуның белән Бөек Британияне Германия авиациясенең көчле һөҗүменнән саклыйлар, дип белдерде.

Квебек провинциясенең баш министры Годбаут үзенең кыскача речендә канадалыларны Советлар Союзына бик нык ярдәм күрсәтергә чакырды.

Советлар Союзы илчесе иптәш Гусев үзенең речендә митингны оештыручыларга, Эльонора Рузвельт ханымга, Канаданың баш министры Маккензи Кингка һәм Квебек провинциясе баш министры Годбаутка рәхмәт белдерде. Иптәш Гусев гитлеризмны тәмам юк иткәнгә кадәр Советлар Союзының көрәш алып барырга тулысынча карар биргәнлеген күрсәтте.

ТУНИСТА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 23 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгы хәбәр итә:—союзниклар гаскәрләренең Төньяк Африкадагы баш штабының белдерүенә караганда, Англия танклары һәм пехотасы, Тунисның үзәк өлешендә җитәрлек кадәр яхшы коралланмаган француз гаскәрләренә булышлык итү максаты белән, бик тиз алга киткәннәр. Англия гаскәрләре немецларның уң флангысын берничә километрга кысрыклаганнар. Немецлар Ваде-Кәбир үзәне буйлап чигенәләр. Шуннан арырак, көньякта, немец танкларының алга барулары туктатылган. Алар Кайруаннан көньяк-көнбатыштарак француз гаскәрләре өчен кыенлыклар тудырып торган булганнар. 3 көннән бирле дәвам итеп килгән бу сугышларда Америка гаскәрләре дә катнашкан.

Кайруаннан көнбатыштарак күчәр державалары гаскәрләренең бу районнагы француз позицияләренә каршы ясалган яңа атакасы кире кайтарылган.

ЛОНДОН, 23 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгы хәбәрчесенең Тунис фронтыннан хәбәр итүенә караганда, Германиянең француз позицияләре аркылы үтеп чыккан танклары һәм моторлаштырылган пехотасы Сук - Рөбәга пунктына барып җиткәннәр. Бу пункт Силианадан 6 миль чамасы ераклыкта тора. Шулай итеп, Пон-Дю-Фас белән Сук-Рөбәга арасындагы юлдан көнчыгыштарак булган француз позицияләре әле һаман да дошман һөҗүме куркынычы астында торалар. Ләкин французларның башка гаскәрләре немецларның юлын бикләгәннәр. Сук-Рөбәга белән Силиана арасындагы районда зур сугышлар булыр дип көтәләр.

Төньяк Африкада француз гаскәрләре штабының белдерүендә әйтелүенчә, француз гаскәрләре, Англия гаскәрләре ярдәме белән, Тунисның үзәк өлешендә берничә миль алга киткәннәр.

АНГЛИЯ ГАСКӘРЛӘРЕ ТРИПОЛИНЫ АЛГАННАР

ЛОНДОН, 23 январь. (ТАСС). Англиянең Якын Көнчыгыштагы кораллы көчләре командованиесенең белдерүендә кичә иртә белән Англиянең алгы частьларының Триполига кергәнлекләре әйтелә. Кичә 8 нче армия гаскәрләре Кастель Вердене алганнар һәм Триполига көнчыгыштан һәм көньяктан якынлашканнар. Дошманның арттагы зур частьлары Англия гаскәрләрен тоткарларга маташканнар, ләкин сугышлар нәтиҗәсендә чигендерелгәннәр.

Англиянең истребитель-бомбардировщиклары үзләренең хәрәкәтләрен Туниска бара торган яр буендагы юл буйлап көнбатышка чигенүче дошманның транспорт колонналарына каршы юнәлдергәннәр. Дошман колонналары зур югалтуларга дучар ителгән.

АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ ТӨНЬЯК ФРАНЦИЯГӘ ҺӘМ БЕЛЬГИЯГӘ ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 23 январь (ТАСС). Англиянең авиация министрлыгының белдерүендә Англия авиациясенең 22 нче январьда көндез Төньяк Франциягә һәм Бельгиягә зур һөҗүмнәр ясаганлыгы әйтелә. Тернезендагы нефть складларына, Абвильдәге, Сент-Омердагы һәм Шербург якынындагы аэродромнарга бомбалар ташланган.

Бу операцияләрдә Англия, дошманнар, Америка Кушма Штатлары һәм союздаш илләрнең истребитель авиациясенең бик күп эскадрильялары катнашкан.

Ставангер якынында яр буе авиациясенең «Хэмпдэен» маркалы торпедоносец самолеты дошманның бер йөк пароходына һөҗүм иткән. Торпеданың пароходка төшкәнлеге күренгән.

ҺАВАДА АНГЛИЯ—ГЕРМАНИЯ СУГЫШЫ

ЛОНДОН, 24 январь. (ТАСС). Рәсми хәбәргә караганда, 24 нче январьга каршы төндә Англия авиациясе Лориандагы су асты көймәләре базасына яңа һөҗүм ясаган. 20 минут эчендә күп санда фугаслы һәм яндыргыч бомбалар ташланган. Нәтиҗәдә бик күп янгыннар чыккан. Авыр бомбардировщикларның икенче бер берләшмәсе Көнбатыш Германиядәге әһәмиятле хәрби объектларга һөҗүм ясаган.

Германиянең берничә самолеты Көньяк-Көнчыгыш Англиянең кайбер пунктларына бомбалар ташлаган. Аларның берсендә корбаннар бар.

ТРИПОЛИТАНИЯДӘ АНГЛИЯ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 23 январь. (ТАСС). Англиянең информация министрлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген Мисырда Англиянең 8 нче армиясенең Эль-Аламейн янындагы позицияләрдән һөҗүм башлавына нәкъ 3 ай тулган. Һөҗүм башланганнан соң 4 атна үткәч Бенгази порты алынган. Англия гаскәрләре Триполига кадәр булган араны 5 атнадан артыграк вакыт эчендә үткәннәр.

Эль-Аламейн турысында һөҗүм башлаганнан соң 90 көн эчендә Англия армиясе 1.400 миль алга киткән. 3 ай эчендә Мисырга һәм Якын Көнчыгышка булган куркыныч бетерелгән, дошманның көчле армиясе бастырылган һәм зур стратегик әһәмияте булган бик күп территория алынган.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, бүген иртә белән Англиянең 8 нче армиясе үзенең көчләрен яңадан оештырып, дошманга каршы яңа һөҗүм башларга җыена булса кирәк.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

◇ 1942 нче елда Копенһагенда (Дания) һәм аның тирә-ягында 8.670 кеше кулга алынган. Илдә Германиягә җибәрелә торган азык тутырылган складларны ут төртеп яндыру вакыйгалары бик ешаеп киткән.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29 секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75. промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60

ПФ 623 КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 721